| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| 423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38 тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13 | | 423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38 тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13 |


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 07 » 02 2024 ел №102

«Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге территориясендә
җирләү эше мәсьәләләре буенча
махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге
тәртибен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм күмү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, 1999 елның 30 мартындагы «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында»гы 52-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 1996 елның 29 июнендәге «Үлгән кешеләрне җирләү буенча хезмәт күрсәтүгә гражданнарның хокукларын гарантияләү турында»гы 1001 санлы Указы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, җирләү эше өлкәсендә муниципаль хокукый актларны камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт итеп «Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесе» Муниципаль унитар предприятиесен билгеләргә ОГРН: 1081688700170, ИНН: 1642003487, КПП: 164201001).

2. «Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесе» Муниципаль унитар предприятиесе Директорына тәкъдим итәргә:

- «Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесе» Муниципаль унитар предприятиесе Уставына тиешле үзгәрешләр кертергә;

- Ютазы муниципаль районында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге, Татарстан Республикасы буенча РФ Социаль фонды бүлекчәсенең Ютазы

районында клиентлар хезмәте (бүлек хокукларында), җирләү эшләре мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең йөкләнгән бурычларын үтәү өлешендә авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек турында шартнамәләр төзү;

- «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибе расланган әлеге карар нигезендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең йөкләнгән бурычларын үтәү өлешендә эшчәнлек алып барырга.

3. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
_____ 20___ ел №___
карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлегенең әлеге тәртибе (алга таба - Тәртип) үлгәннәрнең (һәлак булганнарның) мәетләрен (җәсәдләрен) күмү (күчереп күмү) белән бәйле мөнәсәбәтләрне тулы күләмдә җайга сала.

2. Махсуслаштырылган хезмәт үз эшендә 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм күмү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, 1999 елның 30 мартындагы «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында»гы 52-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 1996 елның 29 июнендәге «Үлгән кешеләрне җирләү буенча хезмәт күрсәтүгә гражданнарның хокукларын гарантияләү турында»гы 1001 санлы Указы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән җитәкчелек итә.

3. Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең бурычлары түбәндәгеләр:

- җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеген үз эченә алган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге халкына һәркем куллана алырлык ритуаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү;

- билгеләнгән үрнәктәге җирләү турында таныклык булган очракта, мәрхүмнәрнең традицияләргә, гореф-гадәтләргә туры китереп дини зиратларда, тугандаш каберлекләрдә җирләү турындагы ихтыярын үтәүне тәэмин итү;

- җирләү буенча хезмәтләргә заказлар кабул итү һәм аларны үтәү буенча документларның архив фондын формалаштыру һәм саклау;

- тиешле хезмәтләрне сыйфатсыз башкарган очракта, кимчелекләрне үз көчләре белән һәм үз хисабына бетерү;

- гражданнарга гарантияләнгән исемлек чикләрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм шартлары, шулай ук гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә башка хезмәтләр турында мәгълүмат җиткерү;

- эшләр башкаруның куркынычсызлык кагыйдәләрен, санитар-гигиена нормаларын һәм кешеләрнең сәламәтлеген саклау таләпләрен үтәү.

4. Махсуслаштырылган хезмәт әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә ярашлы рәвештә «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җәмәгать зиратларында үлгән гражданнарны җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеген күрсәтә.

5. Мәрхүмне җирләү бурычын үз өстенә алган ир яисә хатынга, якын туганнарына, башка туганнарына, законлы вәкиленә яки башка затка җирләү буенча түбәндәге хезмәтләр исемлеген түләүсез күрсәтү гарантияләнә:

- җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;
- гәүдәне каплау, кәфенләү;
- табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү;
- мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендәге зиратка китерү;
- күмү (кабер казу һәм җирләү).

6. Мәрхүмнең ире яисә хатыны, якын туганнары, башка туганнары яки законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан күмүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда, өйдә, урамда яисә башка урында үлгән кешене күмгәндә, эчке эшләр органнары аның шәхесен билгеләгәннән соң, күмүне гамәлгә ашыру бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда, Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, үлем сәбәбен билгеләгәннән соң өч тәүлек эчендә махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7. Шәхесе Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вакытта эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән мәрхүмнәрне җирләү, әлеге органнарның ризалыгы белән, махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан башкарыла.

8. Махсуслаштырылган хезмәт хезмәткәрләре махсуслаштырылган хезмәттән ритуаль хезмәтләр, шул исәптән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегенә кергән түләүле хезмәтләр сатып алырга мәҗбүр итәргә (йөкләргә) хокуклы түгел.

9. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегендәге хезмәтләр мөрәҗәгать иткән көнне махсуслаштырылган хезмәт хезмәткәре тарафыннан махсуслаштырылган хезмәтнең урнашкан адресы буенча гамәлгә ашырыла.

10. Махсуслаштырылган хезмәт хезмәткәре махсуслаштырылган хезмәткә мөрәҗәгать иткән затка консультатив ярдәм күрсәтә:

- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтү тәртибе буенча;
- зиратларның эш кагыйдәләре буенча;
- күмү һәм җирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә гражданнарга түләнә торган җирләүгә социаль пособие һәм бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү тәртибе һәм күләме буенча.

11. Җирләү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегендәге хезмәтләрне алу өчен мөрәҗәгать итүчегә махсуслаштырылган хезмәткә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

- Җирләү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияле исемлегендәге хезмәтләрне алу өчен әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча гариза;
- үлем турында белешмәнең төп нөсхәсе (форма № 11);
- үлем турында таныклык күчермәсе;

- мәрхүмнең паспорт күчермәсе;
- гариза бирүченең паспорт күчермәсе;
- үлем вакытына эшләмәүче пенсионерлар өчен СНИЛС күчермәсе (булган очракта)
- үлем вакытына эшләүчеләр өчен хезмәт кенәгәсе күчермәсе.

12. Махсуслаштырылган хезмәт хезмәткәре җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерә, җирләү датасын һәм вакытын үлгән кешенең гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә, шулай ук диненә туры китереп билгели. Документларны рәсмиләштерү нәтиҗәләре буенча махсуслаштырылган хезмәт әлеге Тәртипнең 6 пунктына ярашлы рәвештә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтә.

13. Махсуслаштырылган хезмәттә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- милек хокукында, аренда яки башка законлы нигездә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтүгә заказларны кабул итүнең тиешле шартларын тәэмин итүче махсус җиһазландырылган биналар;
- хезмәтләр күрсәтү өчен махсуслаштырылган транспорт;
- хезмәтләр күрсәтү өчен персонал;
- туры телефон элемтәсе;
- түбәндәге мәгълүмат белән элмә такта: оешманың исеме, урнашу урыны (юридик адрес), шулай ук эш режимы.

14. Махсуслаштырылган хезмәтнең җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтүгә заказлар кабул ителә торган махсус хезмәт бинасында түбәндәге мәҗбүри мәгълүмат күзәтү өчен ачык урында булырга тиеш:

- 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм күмү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон;
- 1992 елның 07 февралендәге «Кулланучылар хокукларын яклау турында»гы 2300-1 санлы Россия Федерациясе Законы;
- Россия Федерациясе Президентының 1996 елның 29 июнендәге «Үлгән кешеләрне җирләү буенча хезмәт күрсәтүгә гражданнарның хокукларын гарантияләү турында»гы 1001 санлы Указы;
- җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияле исемлеге;
- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтү өчен кулланыла торган, җитештерелә торган һәм гамәлгә ашырыла торган җирләү билгеләнешендәге әйберләрнең үрнәкләре (модельләре) яки аларның фотолары
- гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлегеннән тыш күрсәтелә һәм бирелә торган ритуаль хезмәтләргә һәм ритуаль әйберләргә прейскурант;
- җирләү вакытында кулланыла торган әйберләр (табут, веноклар, кабер өстенә һәйкәлләр һ.б.) турында санитар-эпидемиологик нәтиҗәләр булуы турында мәгълүмат.

15. Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең хокуклары:

- билгеләнгән тәртиптә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле матди-техник базаны сатып алу яки арендага алу;
- җирләүгә заказларны кабул итү пунктлары, ритуаль әйберләр сату буенча кибетләр эшен оештыру;
- гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен кире кайтару;

- гамәлдәге законнарга каршы килмәсә, аңа йөкләнгән бурычларны үтәүгә башка оешмаларны яки шәхси эшмәкәрләрне җәлеп итү.

16. Күмү һәм җирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен махсуслаштырылган хезмәт гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә җаваплы.

«Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
территориясендә җирләү эше мәсьәләләре
буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибенә
кушымта

(Форма)

___________________________________________
(махсуслаштырылган хезмәтнең һәм махсуслаштырылган хезмәт җитәкчесе вазифасының исеме)

________________________________________

___________________________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А.)

адрес:____________________________________
тел.______________________________________

Гариза

Сездән 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм күмү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә,______________________________ _______________________________________________адресы буенча теркәлгән мәрхүм ______________________________________________________________________________
(Ф.И.А., туган елы)
күмү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегендәге хезмәтләрне түләүсез нигездә күрсәтүегезне сорыйм.

Кушымта:
- үлем турында белешмәнең төп нөсхәсе (форма № 11);
- үлем турында таныклык күчермәсе;
- мәрхүмнең паспорт күчермәсе;
- гариза бирүченең паспорт күчермәсе;
- үлем вакытына эшләмәүче пенсионерлар өчен СНИЛС күчермәсе (булган очракта)
- үлем вакытына эшләүчеләр өчен хезмәт кенәгәсе күчермәсе.

______________________ /__________________________________________/
(имза) (имзаны раслау)

«___»______ 20__ ел